КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 май г.Казань № 408

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 сентябрь, 661 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче; 2015 ел, 30 апрель, 309 нчы; 2015 ел, 31 декабрь, 1038 нче; 2016 ел, 25 май, 350 нче; 2017 ел, 15 февраль, 81 нче, 2017 ел, 13 июль, 491 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 1-бүлү (елга 1 тапкыр) «Эш хакы күләмнәре буенча хезмәткәрләр санын бүлү турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формасына, аны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 24 декабрь, 1213 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына:

бастырып чыгарыла торган хисаплар исемлеген, шулай ук «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасы (алга таба – Система) күрсәткечләре реестрын Система инструментлары ярдәмендә алып баруны гамәлгә ашырырга;

Системада аның функционалы ярдәмендә хисапларны визуальләштерү өчен яңа гаризаларны карауны тәэмин итәргә;

мәгълүматлар җибәреп торучысы булып Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты торган Системаның мәгълүмат ресурсларын (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең электрон интерактив паспортлары күрсәткечләрен кертеп) үз вакытында тулыландыруны тәэмин итәргә;

«Татарстан Республикасы товарларын тышкы базарларга чыгару» мәгълүмат-аналитика системасы мәгълүматларын актуальләштерүне тәэмин итәргә;

«Электрон хуҗалык кенәгәсе» мәгълүмат-аналитика системасы мәгълүматлары базасын тулыландыруның даими мониторингын тәэмин итәргә;

2019 елда мәгълүмат ресурсын (мәгълүматлар базасын) республика дәүләт статистика күзәтүенең түбәндәге формалары нигезендә формалаштырырга:

1-хәйрия (еллык) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының хәйрия эшчәнлеге турында мәгълүмат»;

1-ДС (квартал) «Предприятиенең өстәлгән кыйммәте турында мәгълүматлар»;

1-торак фонды-рег (еллык) «Торак фондын файдалану һәм аның сакланышын тәэмин итү турында мәгълүматлар»;

1-инвест-рег (квартал) «Чит илләрдән инвестицияләр турында мәгълүматлар»;

1-ИП-р (бер тапкыр бирелә торган) «Индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеге турында мәгълүматлар»;

1-НП (2 елга 1 тапкыр) «Торак пункт турында мәгълүматлар»;

1-бүлү (елга 1 тапкыр) «Эш хакы күләмнәре буенча хезмәткәрләр санын бүлү турында мәгълүматлар»;

№ 1-РГ (еллык) «Йөрү максатлары буенча гражданнарны урнаштыру һәм туристлык хезмәте күрсәтүләрне яхшырту ысуллары турында мәгълүматлар»;

3-фермер (кыска) (айлык) «Терлекчелек продукциясе җитештерү, терлек һәм кош-корт саны турында мәгълүматлар»;

7-ВЭС (еллык) «Товарлар экспорты турында мәгълүматлар»;

14-мет (ватыклар)-р (бер тапкыр) «Кара һәм төсле металл ватыклары барлыкка килү, аларны хәзерләү һәм файдалану турында мәгълүматлар»;

14-р «Халык хуҗалыкларында терлекләрнең һәм кош-кортларның баш санын, чәчү мәйданнарын бәяләү турында мәгълүматлар»;

24-СХ (МП) (еллык) «Терлекчелек торышы турында мәгълүматлар»;

эшмәкәрлек проблемаларын өйрәнү анкетасы (бер тапкыр бирелә торган);

лицензияләү хезмәтләре күрсәтү сыйфатын бәяләү анкетасы (бер тапкыр бирелә торган);

ИПП (айлык) «Сәнәгать җитештерүе индекслары»;

П-1 (СХ)-р (айлык) «Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм төяп җибәрү турында мәгълүматлар»;

ПМ (квартал) «Кече предприятие эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

1-ДС (ярты еллык) «Россия Федерациясе төбәкләреннән, чит илләрдән кертелә торган чимал һәм материаллар, комплектлау әйберләре, ярымфабрикатлар, ягулык-энергетика ресурслары (ЯЭР) турында мәгълүматлар» формасына кушымта;

мәгълүмати материалларны 2019 елга исемлек нигезендә эшләргә;

әлеге карар кабул ителгән көннән утыз көн эчендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештереп, республика дәүләт статистика күзәтүенең бу карар белән расланган формаларын тутыру буенча тәгълимнамәләр эшләргә;

мәгълүмати материалларны https://ias.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурындагы «Мәгълүмати статистика ресурсы» рубрикасында яки Системада урнаштырырга;

республика дәүләт статистика күзәтүе формалары исемлеген, формаларын һәм аларны тутыру буенча тәгълимнамәләрне http://monitoring.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

карарга 1-ИЭ-р «Индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеге турында мәгълүматлар» һәм 14-р «Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм төяп җибәрү турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формаларын (карарга теркәләләр) өстәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган https://ias.tatar.ru адресы буенча «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында һәм Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурындагы «Мәгълүмати статистика ресурсы» рубрикасында 2019 елда дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты тарафыннан урнаштырыла торган мәгълүмати материаллар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 7.8 нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «7.8. | «Индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеге турында кайбер мәгълүматлар» таблица материалы | республика | бер елга бер тапкыр | 27.09.2019». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин